ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

15 05 2020 г. № 107

2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорында Түбән Кама шәһәре муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында

Россия Федерациясе Президентының «2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорында керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру хакында» 2020 елның 17 апрелендәге 272 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорында керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру хакында» 2020 елның 24 апрелендәге ПУ-250 номерлы Указы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советының «2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорында керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру һәм Түбән Кама шәһәр Советының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 29 апрелендәге 31 номерлы карары белән, карар бирәм:

1. Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2014 елның 15 декабрендәге 190 номерлы карары белән расланган, муниципаль учреждение (бюджет, автоном) җитәкчесе вазыйфасына, шулай ук муниципаль учреждение (бюджет, автоном) җитәкчесе булып эшкә керүче зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үзенең иренең (хатынының) һәм балигъ

булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру тәртибе турында Нигезләмә белән билгеләнгән 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорында Түбән Кама шәһәре муниципаль учреждениеләре житәкчеләре тарафыннан үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшыру срогын 2020 елның 1 августына кадәр (1 августны да кертеп) озайтырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Житәкче Д.И. Баландин